ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 03.10.2024
1520 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә җирләү эше мсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт турында

«Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына Алабуга муниципаль районы җирлекләре Башкарма комитетлары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы килешүне гамәлгә ашыру максатында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җаваплы итеп Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль планлаштыру бүлеген билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 5D5B832C0D4CC8A96C405A04F5061337
Владелец: Томилин Андрей Александрович
Действителен с 25.09.2024 до 19.12.2025

Житәкче вазифаларын башка... А.А. Томилин

Алабуга муниципаль
районы Башкарма комитеты
карары белән расланды
03.10.2024
1520

**Алабуга муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе**

Элеге тәртип «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

## 1 нче бүлек.
## Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтне (алга таба – махсуслаштырылган хезмәт) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты башкара. Махсуслаштырылган хезмәт җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеген түләүсез нигездә күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

Үз эшчәнлегендә махсуслаштырылган хезмәт Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту буенча методик тәкъдимнәргә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 1 апрелендәге 64/0 номерлы боерыгына таянып җитәкчелек итә.

1.2. Махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль акты белән раслана.

1.3. Махсуслаштырылган хезмәт физик яисә юридик затлар белән

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге кысаларында эшләр башкаруга контрактлар (килешүләр) төзи.

## 2 нче бүлек.
## Махсуслаштырылган хезмәтнең төп функцияләре һәм бурычлары

2.1. Җирләү эше өлкәсендәге вәкаләтләрнең бер өлешен район дәрәҗәсенә тапшыру турында килешүләр төзелгән җирлекләрнең җәмәгать зиратларында махсуслаштырылган хезмәт җирләү буенча түбәндәге хезмәтләр исемлеген түләүсез нигездә күрсәтә:

1) җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;
2) каберне һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү;
3) вафат булган (үлгән) кешенең гәүдәсен (мәетне) зиратка илтү;
4) җирләү.

2.2. Үлгән кешенең ире яисә хатыны, якын туганнары, башка туганнары яисә законлы вәкиле булмаганда яисә аларның җирләү мөмкинлеге булмаганда, шулай ук өйдә, урамда яки башка урында мәетне җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда, эчке эшләр органнары аның шәхесен билгеләгәннән, үлем сәбәпләре ачыкланганнан соң, җирләү махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан өч тәүлек дәвамында башкарыла, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса.

2.3. Шәхесләре Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вакытта эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнмәгән үлгәннәрне җирләү, әлеге органнарның ризалыгы белән, махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан мондый очраклар өчен билгеләнгән җәмәгать зиратларында җирләү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.4. Әлеге тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән вафат булган кешеләрне җирләгәндә махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;
2) мәетне төрү (киендерү);
3) табут бирү;
4) вафат булган кешене зиратка илтү;
5) җирләү.

2.5. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлегее күрсәтү махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан закеннарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда башкарыла.

## 3 нче бүлек.
## Махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга таләпләр

3.1. Махсуслаштырылган хезмәт күмү һәм җирләү эше өлкәсендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль хокукый

актлар таләпләрен үтәргә тиеш, шул исәптән:

- түләүсез нигездә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген бирү буенча дәүләт гарантияләре;

- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлегенә кергән хезмәтләрнең сыйфатына карата таләпләр.

3.2. Махсуслаштырылган хезмәтнең кирәкле акчалар булмау сәбәпле яки башка нигезләр буенча, гарантияләнгән хезмәтләр исемленнән баш тартуы рөхсәт ителми.

3.3. Махсуслаштырылган хезмәт түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) вафат булган кешенең ихтиярын үтәүче, шулай ук вафат булган кешенең ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкилләре, вафат булган кешене җирләү бурычларын үз өстенә алган башка затлар исеменнән һәм аларның кушуы буенча эш итүче затларга җирләүне гамзлгә ашыруга (шул исәптән вафат булган кешене җирләү юлы белән) каршылык күрсәтергә (комачауларга);

2) махсуслаштырылган хезмәттән ритуаль хезмәтләр, шул исәптән җирләү буенча хезмәтләр исемлегенә кергән хезмәтләрне сатып алуны мәҗбүр итәргә (ирексезләп кушарга).

**4 нче бүлек.**
**Махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибенә төп таләпләр**

4.1. Махсуслаштырылган хезмәт җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерә, күмү датасын һәм вакытын, гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә, шулай ук мәрхүмнең диненә туры китереп билгели.
Документларны рәсмиләштерү нәтиҗәләре буенча махсуслаштырылган хезмәт әлеге тәртипнең 2 бүлегенә ярашлы рәвештә җирләү буенча хезмәт күрсәтә.
4.2. Махсуслаштырылган хезмәт консультатив ярдәм күрсәтә:
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтү тәртибе буенча;
зиратларның эш кагыйдәләре буенча;
җирләүгә социаль пособие бирү тәртибе һәм күләме буенча һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә җирләү һәм күмү эше өлкәсендә гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү тәртибе буенча.
4.3. Махсуслаштырылган хезмәт бинасында күренеп тора торган урында түбәндәге мәҗбүри мәгълүмат булырга тиеш:
1) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;
2) «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон;
3) Россия Федерациясе Президентының «Гражданнарның үлгәннәрне җирләү буенча хезмәтләр күрсәтү хокукларының гарантияләре турында» 1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы Указы;

4) җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге.

**5 нче бүлек.**
**Махсуслаштырылган хезмәтнең җаваплылыгы**

Җирләү һәм күмү эше өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен махсуслаштырылган хезмәт гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә җаваплы булалар.